КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 сентябрь г.Казань № 825

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 17 август, 590 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 17 август, 590 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 август, 641 нче; 2019 ел, 16 апрель, 298 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 нче пунктта:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$\sum C_{рсу}$ – интеллектуаль милек белән идарә итүнең корпоратив системасын булдыру буенча проект алды тикшеренүләрен үткәрүне, предприятиеләрнең интеллектуаль милек белән идарә итү инфраструктурасының автоматлаштырылган эш урыннарын программалы тәэмин итүнең махсуслаштырылган модульләрен эшләүне һәм файдаланучыларга интеллектуаль милек белән идарә итүнең автоматлаштырылган веб-интерфейс системасына керү мөмкинлеген, интеллектуаль милек белән идарә итүнең автоматлаштырылган веб-интерфейс системасын үстерүгә һәм алып баруга техник бирем эшләүне үз эченә алган интеллектуаль милеккә хокуклар белән идарә итү системасын булдыру чыгымнарының гомуми суммасы,»;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$C_{ом}$ – интеллектуаль милек белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы белгечләрен өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча укытуны, шулай ук методик материаллар эшләүне үз эченә алган, белем бирү чараларын үткәрү буенча эшләр башкаруның гомуми кыйммәтеннән барлыкка килгән интеллектуаль милек өлкәсендәге белем бирү чараларын үткәрү чыгымнары;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$C_{по}$ – технологик инновацияләрне гамәлгә ашыру өлкәсендәге мәсьәләләрне ачыклау, алга таба предприятиеләр продукциясен сату базарларына чыгару өчен бәя бирү максатыннан чыгып, интеллектуаль эшчәнлекне инвентарьлаштыру һәм аның саклауга сәләтле нәтиҗәләрен билгеләү өчен предприятиеләрне тикшерүләрне үткәрүнең түбәндәге формула буенча билгеләнә торган чыгымнары:»;

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$\sum C_{рпо}$ – предприятиеләрне тикшерүне үткәрү өчен техник бирем эшләүне һәм раслауны, җитештерү номенклатурасын билгеләүне, патент тикшеренүләре үткәрүне һәм интеллектуаль милек булдыру өчен ресурсларны билгеләүне, шулай ук предприятиеләрне фәнни-технологик үстерү программаларын эшләү һәм аларның продукциясен интеллектуаль милек өлешендә сату базарларына чыгару буенча тәкъдимнәр эшләүне үз эченә алган предприятиеләрне тикшерү чыгымнарының гомуми суммасы,».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин